298

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

**1 статья.** «Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында» Татарстан Республикасының 1999 елның 27 маендагы 2192 номерлы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999 ел, № 6), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. Уен бизнесына айлык салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

һәр уен өстәле өчен – хезмәткә түләүнең 400 минималь күләмендә;

һәр уен автоматы өчен – хезмәткә түләүнең 15 минималь күләмендә;

һәр тотализатор кассасы өчен – хезмәткә түләүнең 400 минималь күләмендә;

букмекер конторасының һәр кассасы өчен – хезмәткә түләүнең 200 минималь күләмендә».

**2 статья.** Бу Закон рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач, ләкин уен бизнесына салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан алда булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 июне
№ 950